РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

**ЧИСТОПОЛЬСКИЙ ГОРОДСКОЙ ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

**ЧИСТАЙ ШӘҺӘРЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

***Постановление*** ***Карар***

30.11.2022 **г. Чистополь** № 189

Чистай шәһәре Башкарма комитетының «Стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыру схемасын раслау турында» 2016 елның 27 июнендәге 96 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясендә сәүдә эшчәнлеген дәүләт җайга салуы нигезләре турында» 2009 елның 28 декабрендәге 381-ФЗ номерлы Федераль законның 10 статьясын, Татарстан Республикасы сәнәгать һәм сәүдә министрлыгының «Татарстан Республикасы җирле үзидарә органнары тарафыннан стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыру схемасын эшләү һәм раслау тәртибен раслау турында» 2011 елның 26 февралендәге 34-ОД номерлы боерыгын, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Муниципаль милектәге җирләрдә яки җир кишәрлекләрендә, шулай ук дәүләт милке чикләнмәгән җирләрдә яки җир кишәрлекләрендә стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыру тәртибен раслау турында» 2016 елның 13 августындагы 553 номерлы, «Муниципаль милектәге җирләрдә яки җир кишәрлекләрендә, шулай ук дәүләт милке чикләнмәгән җирләрдә яки җир кишәрлекләрендә стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыру тәртибенә үзгәрешләр кертү турында» 2017 елның 18 сентябрендәге 675 номерлы карарлары нигезендә, Чистай шәһәре Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. Чистай шәһәре Башкарма комитетының «Стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыру схемасын раслау турында» 2016 елның 27 июнендәге 96 номерлы карары белән расланган стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыру схемасына үзгәрешләр кертергә,
- 41 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итеп:

| № т/б | Стационар булмаган сәүдә объектының урнашу урыны | Сатыла торган товарның ассортименты | Стационар булмаган сәүдә объекты тибы | Сәүдә урыннары саны | Стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыру вакыты |
|---|---|---|---|---|---|
| 41. | Чистай шәһәре, К. Маркс ур., 92 | азык-төлек товарлары | сәүдә ракушкасы | 340 | ел дәвамында |

- 42 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итеп:

| № т/б | Стационар булмаган сәүдә объектының урнашу урыны | Сатыла торган товарның ассортименты | Стационар булмаган сәүдә объекты тибы | Сәүдә урыннары саны | Стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыру вакыты |
|---|---|---|---|---|---|
| 42. | Чистай шәһәре, К. Маркс ур., 92 | азык-төлек булмаган товарлар | сәүдә күшәге | 38 | ел дәвамында |

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының рәсми сайтында (http://chistopol.tatar.ru/) урнаштырырга һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Чистай шәһәре Башкарма комитетының сәүдә, мәдәният, яшьләр сәясәте, спорт һәм туризм бүлеге баш белгече Ю.Ю. Әхмәтовага йөкләргә.

Шәһәр Башкарма комитет
җитәкчесе И.Ф. Рәхимов